**ИСПОНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СУКСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422729, Республика Татарстан, Высокогорский район
с. Суксу, ул. Школьная, 9А

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СУЫКСУ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422729, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Суыксу авылы, Мәктәп ур, 9А

Тел./факс: +7(84365) 61-8-43, e-mail:Suks.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**21 февраль 2023 ел** **№ 3**

## Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге башкарма комитеты карарының үз көчен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Россия Федерациясендә Янгынга каршы режим кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 24.10.2022 №1885 карары нигезендә, прокурор тәкъдиме белән бәйле рәвештә Биектау районы хокук чыгару инициативасы тәртибендә, Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге башкарма комитеты,

**КАРАР ИТӘ:**

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

Суыксу авыл җирлеге башкарма комитетының 26.03.2021 ел, № 7 карары «Суыксу авыл җирлеге территориясендә чүп-чарны, үләнне, яфракларны һәм башка калдыкларны, материалларны яисә эшләнмәләрне яндыру урынын һәм ысулларын билгеләү турында»

Суыксу авыл җирлеге башкарма комитетының 09.06.2021 ел № 16 карары «Биектау муниципаль районының Суыксу авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 26 мартындагы 7 номерлы «Суыксу авыл җирлеге территориясендә чүп-чарны, үләнне, яфракларны һәм башка калдыкларны, материалларны яисә эшләнмәләрне яндыру урынын һәм ысулларын билгеләү турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында»

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар 2023 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Суыксу авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе Р.С.Низамиев